ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

15 05 2019 г. № 234

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Күпфатирлы йорттагы урыннарны үзгәртеп төзү һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6-нчы кушымта)»;

карарның 6-нчы кушымтасында:

административ регламент исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йорттагы урыннарны үзгәртеп төзү һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»;

регламентның 1.1., 2.1., 2.3., 2.5., 2.6., 2.9., 3.1.2., 3.3.1. пунктчаларында «торак урыны» сүзләрен «күпфатирлы йорттагы урыннар» сүзләренә алмаштырырга;

2.5. пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән һәм рәсмиләштерелгән күпфатирлы йортта үзгәртеп төзелә торган һәм (яки) үзгәртеп планлаштырыла торган урынны яңадан төзү һәм (яисә) үзгәртеп планлаштыру проекты, әгәр күпфатирлы йортта

бинаны үзгәртеп төзү һәм (яисә) үзгәртеп планлаштыру әлеге урынны күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнең бер өлешен кушудан башка мөмкин булмаса, шулай ук күпфатирлы йортта урыннарның милекчеләре гомуми җыелышының Россия Федерациясе Торак кодексының 40 статьясындагы 2 кисәгендә каралган күпфатирлы йортта урыннарның барлык милекчеләренең мондый үзгәртеп коруга һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруга ризалыгы турында беркетмәсе»;

2.5. пунктның 6, 8 пунктчаларын төшереп калдырырга;

2.6. пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) әгәр аңа хокук күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлгән булса, күпфатирлы йортта яңадан төзекләндерелә торган һәм (яки) үзгәртеп планлаштырыла торган урынгы хокук билгеләүче документлар»;

2.5., 3.12. пунктларында «(1-нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3., 3.1.7. пунктларында «(2-нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1.8. пунктларында «(3-нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга;

регламентның 1-3-нче кушымталарын төшереп калдырырга;

2. Җәмәгатьчелек һәм гаммәви мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044574